КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 15 гыйнвар г.Казань № 2

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 204 нче; 2012 ел, 28 май, 425 нче 2012 ел, 25 август, 737 нче; 2013 ел, 14 ноябрь, 874 нче; 2014 ел, 7 июнь, 389 нчы; 2016 ел, 13 август, 557 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1050 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 912 нче; 2018 ел, 12 май, 352 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 956 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турындагы нигезләмәгә, 1.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе үз компетенциясе чикләрендә, максатлар һәм бурычларның өстенлеген исәпкә алып, товар базарларында көндәшлекне үстерүгә ярдәм күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин